| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2021 елның 11 ноябре № 13/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән чәке авыл җирлегенең Генераль планы «Максима» ЖЧЖ тәкъдим иткән материалларны карап, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2021 елның 25 октябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2021 елның 29 октябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 7 һәм 29 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Генераль планын территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (www.droganoye.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге бүлегендә бастырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров